Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№14 (65)

25 апрель 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

**22 АПРЕЛЬ** көнне **КФУГА ENGLISH FIRST КОМПАНИЯСЕ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ** килде. Кунаклар компанияләре, Татарстанда тормышка ашырыла торган проектлары турында сөйләде. Компания Казан университетына инглиз теле укытучыларының квалификацияләрен күтәрү өлкәсендә хезмәттәшлек итәргә тәкъдим итте.

• • • •

**ЯР ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫНЫҢ** филология һәм журналистика факультетының 2-4 курс **СТУДЕНТЛАРЫ БЕРЕНЧЕ ЯШЬ ЖУРНАЛИСТЛАР ФОРУМЫНДА КАТНАШТЫ**. Форум кысаларында студентлар журналистика өлкәсендә үзләренең профессиональ осталыкларын арттырды.

• • • •

**22 АПРЕЛЬ** көнне Казанда узачак **УНИВЕРСИАДА ОБЪЕКТЛАРЫНА** һәм **ЧАРАЛАРАРЫНА** керү мөмкинлеге бирә торган **БЕЙДЖИКЛАР БИРҮ ПРОЦЕССЫ** башланды. Беренче булып, аккредитация үзәгендә бейджикларны КФУның проректорлары һәм институт директорларына тапшырдылар. Әлеге бейджикларда аккредитация категориясе, Универсиада объектларына керү зоналары күрсәтелгән.

• • • •

**22 АПРЕЛЬ КӨННЕ** Туринда (Италия) **«АЛЬТАИР-2013» VI ТЕХНОЛОГИК АЧЫК КОФЕРЕНЦИЯСЕН АЧУ ТАНТАНАСЫ** булды. Анда КФУделегациясе дә катнашты. Аның составында ректор Илшат Гафуров, Яр Чаллы институты директоры Мәхмүт Ганиев, Физика институты директоры урынбасары Дмитрий Таюрский бар. Конференция кысаларында университет вәкилләре төрле семинарларда катнашты.

• • • •

**23 АПРЕЛЬ** көнне Филология һәм сәнгать институтында инглиз теле белгечләренең **III РЕСПУБЛИКА ФОНЕТИК КОНКУРСЫ** узды. Конкурс Казан халыкара лингвистик үзәгендә ФСИның чит телләр кафедрасы житәкчесе, педагогика фәннәре докторы, доцент Д.РСабирова житәкчелегендә оештырылды. Әлеге конкурс быел өченче мәртәбә оештырыла. Анда Татарстанның 22 районыннан барлыгы 230га якын укучы катнашты.

• • • •

**23 АПРЕЛЬ** көнне **IT-ПАРКТА** студентларны эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча **ПРЕСС-КОНФЕРЕНЦИЯ** узды. Анда күптән түгел барлыкка килгән «Студентларның хезмәт биржасы» интернет-ресурсының яңа мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирелде. Әлеге интернет-ресурс студентларга – эш, ә эшмәкәрләргә эшчеләр табу мөмкинлеген җиңеләйтүгә юнәлтелгән.

• • • •

**23 АПРЕЛЬ** көнне, Едитепе (Стамбул, Турция) университетының юридик факультет деканы **ХАЛУК КАБААЛЫОГЛУ** КФУның юридик факультет студентлары һәм укытучыларына **ЛЕКЦИЯ УКЫДЫ**. Визит кысаларында Едитепе университеты профессоры Халук Кабаалыоглу Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты, Филология һәм сәнгать институты эшчәнлеге белән танышты.

• • • •

**23 АПРЕЛЬ** көнне РФдагы **КЫТАЙ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫ ОЕШМАСЫ ВӘКИЛЛӘРЕ** Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтына **ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Делегация составында булган мәгариф эшләре буенча киңәшчеләр Ли Хай һәм Фэн Сянжу институт директоры, тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов белән очрашты. Очрашуда Казан университетының Кытай югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итүе, КФУда Кытайны өйрәнү үзәгенең эшчәнлеген камилләштерү һәм бездә укучы Кытай студентлары турында фикер алышу булды.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*






Алия Галимуллина фотосы

# Коррупция белән көрәшәбез!

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

24 апрель көнне Казан федераль университетында «Коррупциягә каршы көрәштә хокук аспектлары: Россия һәм Европа тәҗрибәсе» темасына түгәрәк өстәл узды.

Чара Россия һәм Нидерландның әйдәп бара торган уку йортлары арасында видеоконференция формасында уздырылуы белән аеруча игътибарга лаек. Мондый форматтагы чара Татарстан республикасында беренче тапкыр үткәрелә, шуңа да ул фәнни һәм гамәли яктан зур әһәмияткә ия.

Заманча технологияләр алга киткән чорда дөньяның төрле почмагындагы галимнәрнең эш урыныннан ерак китмичә, бер-берсе белән фикер алышу мөмкинлеге бар. Безнең очракта да өч университет вәкилләре видео аша берберсен күреп сөйләшә, сораулар бирә, фикер алышуда катнаша алды. Бүгенге көндә коррупция халыкара дәрәҗәдә глобаль масштаблы проблемага әйләнеп бара. Шуңа күрә түгәрәк өстәл темасының актуальлеге беркемдә дә шик уятмыйдыр.

Видеоконференциядә КФУның юридик факультеты, Ассер тикшеренү университеты (Гаага) һәм Маастрихт университеты (Маастрихт) галимнәре, әлеге өлкәдә халыкара белгечләр, ТР Югары суд, ТР Юстиция министрлыгы һәм республиканың хокук саклау органнары вәкилләре белән беррәттән, адвокатлар, аспирантлар, магистрлар, студентлар һәм киң юридик җәмәгатьчелек катнашты. Юридик факультет директоры Илдар Тарханов чит ил коллегаларын һәм барлык катнашучыларны сәламләде һәм фикер алышу объекты булачак мәсьәләнең мөһимлеген билгеләп үтте: «Коррупция проблемасы милли төсмер йөртсә дә, нигездә, ул һәр ил өчен универсаль. Шуңа күрә безгә, әлеге иҗтимагый афәт белән көрәшү юлларын эзләгәндә, чит ил коллегаларыбызның тәҗрибәсе комачау итмәячәк».

Алга таба белгечләр аерым темаларга тукталып, доклад рәвешендә чыгыш ясадылар. Маастрихт университеты профессоры Ханс Нелен «Коррупция нәрсә ул?» дигән сорауга җавап бирергә тырышты һәм аның белән көрәшү юлларын эзләде. «Коррупция – дәүләтнең көчсезлек билгесе ул! Аның киңлеген һәм тирәнлеген билгеләү бик авыр. Бу күренешне бетерү өчен, реформалар булдыру, әлбәттә, уңай күренеш. Минемчә, иң беренче чиратта, әлеге проблеманы барлыкка китерә торган сәбәпләрдән арынырга кирәк». Аның фикеренчә, бу мәсьәләне хәл итә торган бердәм формат юк. Монда җәмгыять үзенчәлекләрен, аның структурасын истә тотарга кирәк.

Шул рәвешле, конференциядә катнашучылар коррупция белән көрәшү юлларын эзләде. Төгәл җавапны таба алмасалар да, бу күренешне юкка чыгаруга китерерлек байтак чаралар телгә алынды.

## • Хезмәттәшлек

# Agilent Technologies – КФУ партнеры

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Кичә, ягъни 24 апрель көнне, Agilent Technologies компаниясе вәкилләре белән очрашу узды.

Очрашуда иң элек КФУның тышкы багланышлар департаменты директоры А.А.Крылов КФУ турындагы презентация белән чыгыш ясады. Аннан соң сүз Agilent Technologies оешмасы вәкилләренә бирелде. Әлеге компания контроль-үлчәү җиһазлары җитештерү буенча лидерлар рәтендә санала. Agilent Technologies электрон үлчәү, химия анализы, биотехнологияләр һәм геном диагностикасы юнәлешләрендә эшчәнлек алып бара. Бу оешманың университетлар өчен әзер белем бирү курслары һәм материаллары бар. Agilent Technologies вәкилләре сүзләренчә, компаниядә югары уку йортлары галимнәре, укытучылары һәм студентлары өчен интернатура үтү, тикшеренү грантлары алу мөмкинлеге дә тудырылган. Оешма дөньяның берничә университеты белән хезмәттәшлек итә икән инде. Бүген VIII Казан венчур ярминкәсендә КФУ һәм Agilent technologies компаниясе үзара хезмәттәшлек турындагы меморандумга кул куйды.



Алия Галимуллина фотосы

• КФУга 3 ел!

Динара МИННЕКАЕВА,
хәбәрче

# Ирешелгәннәр чик түгел!

2 апрель көнне Казан (Идел буе) федераль университеты оешканга 3 ел тулды.

Яңа статус алып, яңа сулыш белән эшли башлаган федераль уку йортының тарихы бик еракка барып тоташа. Император Александр I Указы белән ачылган белем йорты бик күп дөньякүләм шәхесләр тәрбияләгән биргән. Бүгенге көндә дә, ул үз дәрәҗәсен саклап, горур һәм ныклы адымнар белән алга атлый. Җөмһүриятебезнең берничә зур уку йортларын берләштереп, Казан дәүләт университеты базасында барлыкка килгән федераль уку йортында бүгенге көндә **16 институт**, **5 факультет**, **3 югары мәктәп** бар. Шулар арасында Фундаменталь медицина һәм биология институты, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Физика институты, А.М.Бутлеров ис. Химия институты, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты һ.б. тулысы белән яңа форматта эшли башлады. **КФУ карамагында 400 мең м² мәйданны тәшкил иткән укыту-лабораторияләре** бар. Шушы соңга өч ел эчендә 100дән артык лаборатория сафка баскан. 1 июньдә **Физика институтының В.П.Энгельгардт ис.Астрономик обсерватория территориясендә планетарий ачылачак**. Ул Идел буендагы Космик тикшеренүләр һәм технологияләр үзәгенең беренче комплексы булып тора.

КФУда барлыгы **30 Кече инновацион оешма** бар. Алар медицина технологиясе һәм җиһазлары, мәгълүмати технологияләр, авыл хуҗалыгы, төзелеш буенча эш алып бара. Уку йорты дөньяның 35 иленнән 90нан артык югары уку йорты һәм фәнни үзәкләр белән хезмәттәшлек итә. Гомумән, КФУның **инновацион үсеш юнәлешләре турында сөйләгәндә, алар дүрт:** биотехнологияләр, фармацевтика һәм биомедицина; нефть табу, нефть эшкәртү һәм нефтехимия; мәгълүмати коммуникацион технологияләр һәм инфраструктура; комплексны социогуманитар тикшеренүләр.

Шөкер, федераль дәрәҗәдәге уку йортында Ана телебезгә, мәдәният-әдәбиятыбызга, гореф-гадәтләрне саклап, аларны киләчәк буынга тапшыруга зур игътибар бирелә. Бу, әлбәттә, 2010 елның 9 апреленнән университет ректоры вазифасына билгеләнгән физика-математика фәннәре кандидаты, икътисад фәннәре докторы, ТРның атказанган икътисадчысы **Илшат Рәфкать улы Гафуровның** хезмәт нәтиҗәсе. 2011 елда ачылган **Филология һәм сәнгать институты туган телебезне саклаучы төп үзәк** булып тора. Биредә татар филологиясе бүлеге, тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә татар теле укытучылары гына түгел, ә тәрҗемәчеләр, әдәбият, сәнгать, тел һәм башка төр белгечләр әзерлиләр.

**Уку йорты** республиканың һәм Казаныбызның **база мәктәпләре белән тыгыз элемтәдә** тора. Галимнәребез интернет буенча онлайн-режимда мәктәп һәм гимназия укучылары өчен дәресләр алып бара. Актаныш районы гимназия-интернаты белән бергә гамәлгә кертелгән уртак проектларның нәтиҗәсе мактанырлык.

Шулай ук **«Tatarica» халыкара фәнни журналын** булдыру планы да бар. Биредә татар, рус һәм инглиз телләрендә дөньяның бөтен төбәкләреннән әдәбият, фольклор, татар халкы тарихы һәм мәдәниятенә багышланган фәнни-тикшеренү эшләре, шулай ук дөньяга танылган татар галимнәре турында библиографик мәкаләләр бастыру каралган. Журналны басма һәм электрон вариантта чыгару планлаштырыла.

Казан федераль университеты галимнәре **«Ана теле» проектын** тормышка ашыруда да төп рольне уйный. «Ана теле» проекты – татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен оештырылган on-line мәктәп. Әлеге проектны Татарстан белгечләре Educartion First компаниясе белән берлектә гамәлгә ашыра. Һәр теләгән кеше anatele.ef.com адресы буенча регистрация үтеп, әлеге система ярдәмендә татар телен өйрәнә алачак. Проект ТР Президенты **Рөстәм Миңнеханов куйган бурычны тормышка ашыруны күз алдында тота**. Тагын бер кат басым ясыйсы килә, проектны эшкәртүгә КФУның телче-галимнәре, укытучылары күп хезмәт куя. Телгә өйрәтүне тормышка ашыруның тугыз дәрәҗәсе булачак. Бүгенге көндә шуларның өчесе инде әзер, ел дәвамында калганнары да эшләнеп бетәчәк. Һәр дәрәҗәдә сигез бүлек (тема) бар. Алар эченә дүртәр дәрес кертелгән. Дәресләр гадидән катлаулыга таба бара. Һәр дәрәҗәне үзләштергән саен, өйрәнүченең сертификат алу мөмкинлеге бар.

Казан федераль университетында **татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен курслар да эшли**. Өч айлык түләүсез курслар быел икенче тапкыр оештырылды. Ул телне өйрәнә башлаучылар һәм дәвам итүчеләр өчен ике юнәлештә алып барыла. Курслардан соң, анда катнашучылар махсус тест үтеп, татар теле курсларын тәмамлау турында сертификат ала алачак. Шулай ук ФСИда Татарстан Республикасы Президент аппараты хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курслары да ачылды. Ул «Эшлекле татар теле» һәм «Рус коммуникациясе пространствосында тел шәхесе» программалры буенча старт алды. Әйтергә кирәк, татар телен өйрәнгән белгечләргә башка чит теллләрне (гарәп, төрек, фарсы телләре) өйрәнергә җиңелрәк булачак. Әлеге проектлар да президент **Рөстәм Миңнеханов** һәм Казан университетының **Кайгыртучанлык советы** ярдәмендә тормышка ашырыла. Дәүләт эшлекләләре өч ай дәвамында атнасына дүрт сәгать татар телен өйрәнәчәк.

Казан федераль университеты ректоры **Илшат Гафуровның** тагын бер зур хезмәт нәтиҗәсенә аерым тукталасы килә. Ул – федераль уку йортында атна саен басылып килә торган, безнең уку йорты студентлары гына түгел, ә башка вуздагы яшьтәшләребез һәм мәктәп укучылары, мөгаллимнәр яратып укый торган **«Дарелфөнүн» газетасы**. 2011 елның 6 окятбрендә беренче тапкыр дөнья күргән газетабызның бүгенге көндә мактанырлык уңышлары бар. Ул республикакүләм **«Ел студенты–2012»** премиясендә **«Студентларның иң яхшы массакүләм матбугат чарасы»** номинациясендә җиңү яулады. IV Бөтенроссия «МедиаПокорение» фестивалендә **«Иң яхшы корпоратив басма»** дәрәҗәсен алды.

Өч ел эчендә башкарылган бөтен хезмәтләрне санап чыгуны кирәк дип тапмыйбыз, чөнки федераль университетның нинди темплар белән алга барганы, үскәне, студентлары, галим-мөгаллимнәре алдында нинди мөмкинлекләр ачканы күз алдыбызда. Безнең студентлар заманча таләпләргә туры китереп төзелгән «Универсиада авылы» йортларында яши, иң яхшы спорт залларында сәламәтлекләрен ныгыта, бай китапханәләрдә белемнәрен арттыра, исемле стипендияләр ала, югары дәрәҗәдә җиһазландырылган лабораторияләрдә төрле фәнни-тикшеренү эшләре башкара һ.б. Ләкин ирешелгәннәр моның белән генә чикләнми. Алда безне зур җиңүләр һәм биек үрләр көтә.



■ *ФСИның лингафон кабинетында Р.Миңнеханов һәм И.Гафуров студентлар белән аралаша.*



■ *Он-лайн дәрестә.*



■ *Кунаклар сәнгать бүлеге студентлары яңа табып алып кайткан татар музыка уен кораллары белән таныша.*
Алия Галимуллина фотолары

• Чара

Материалларны **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

# Казан – супрамолекуляр химия үзәге!

23 апрель көнне Россия Фәннәр Академиясенең А.Е.Арбузов ис. Органик һәм физик химия институтында супрамолекуляр һәм координацион химия буенча Француз-Россия симпозиумы ачылды. Докладларның өчтән берен КФУ галимнәре тәкъдир итте.

Форумны Россия Фәннәр Академиясе киңәшчесе Александр Коновалов ачып җибәрде. Ул Казанның супрамолекуляр химия буенча фәнни үзәк булып торуын билгеләп узды.

Бутлеров ис. Химия институтының органик химия кафедрасы җитәкчесе Игорь Антипин КФУ һәм Страсбург университетлары арасындагы үзара хезмәттәшлек хакында сөйләп узды. Аның сүзләренчә, Франция белгечләре белән аралашу 90 еллар ахырынан башланган. Шушы вакыттан ук Казанда супрамолекуляр химия юнәлеше үсеш ала. Дөнья экспертлары Казан галимнәре үткәргән тикшеренү эшләренә югары бәя бирә. Хезмәттәшлек кысаларында 2008 елда Казанга Нобель премиясе лауреаты, Страсбург университеты һәм Колледж де Франс профессоры Жан-Мари Лен килгән иде.

Бүген Казан университеты галимнәре сенсор материаллар булдыру юнәлеше буенча тикшеренү эшләре алып бара. Аларның докладлары нәкъ менә шул өлкәне яктырта.

• Бәйге

# Үзебезнекеләр сынатмады

Күптән түгел Казан федераль университетында «Бөтенроссия суд дебатлары – 2013» модельле суд процессы узды.





Әлеге чара кысаларында гражданлык һәм җинаять процесслары моделе буенча суд утырышлары оештырылды. Беренче тапкыр мондый ярыш 2005 елда уздырылган. Шуннан бирле Казан университеты апрель саен үзенә кунаклар чакыра. Быел да уку йортыбызга, көчләрен сынап карау максатыннан, Россиянең төрле төбәгеннән 120ләп студент килде.

Чараның ачылу тантанасында катнашучыларны КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Данис Нургалиев, юридик факультет деканы Илдар Тарханов сәламләде. Тантанада рәсми кунаклар да күп иде: прокуратура һәм адвокатура органнары, суд корпусы вәкилләре, Россиянең күренекле галимнәре. Дебатларда студентлар, суд эшенә бәйле рәвештә, үз позицияләрен яклады, катнашучыларны хокукый карашларының дөреслегенә инандырды. Судьялар алдында чыгыш ясап, булачак юристларга дәгъвачы һәм җавапка тартылучы ролендә булырга туры килде.

Аяусыз ярышта безнекеләр сынатмады. Гражданлык процессы секциясендә КФУның юридик факультетының 4 курс студентлары Римма Фатыйхова, Мария Шутовская (*сул як рәсемдә*) җиңүгә иреште (алар Мәскәү дәүләт университетыннан килгән кунаклар белән I урынны бүлеште. )

Җинаять эшләре процессы секциясендә исә шул ук факультет студентлары Диана Афонина, Валентин Крайнов һәм Вилена Рукавишникова (*уң як рәсемдә*) беренчелекне яулады. Җиңүчеләрне һәм аларның җитәкчеләрен котлыйбыз!

● Тарих эзләреннән

# Беренче татар ректоры - кем ул?

Гыймаз Баһаветдин улы Баһаветдинов Казан дәүләт университеты тарихына беренче татар ректоры буларак кереп калган.

Ул 1897 елның 27 декабрендә Бондюг посёлогында (хәзерге Менделеев шәһәре) эшче гаиләсендә туа. 12 яшеннән әтисе эшләгән химия заводында 1917 елга кадәр эшли. Бу дәвердә Гыймазга эшче, хисапчы, химия товарлары җитештерү буенча мастер вазифаларын башкарырга туры килә. 1917 елгы революциядән соң, ул партиягә керә һәм заводта һөнәри эшчәнлеген дәвам итә: Бондюг заводы яшьләр союзын оештыра, «Мөселман яшьләре тавышы» газетасы редколлегиясендә әгъза булып тора. 1918 елда Гыймаз Баһаветдиновны Вятка шәһәренең эшче кооперативлар һәм фабрика-заводлар комитетына делегат итеп сайлыйлар. Биредә ул Вятка губернасының сәнәгать бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Шул ук елны, авыру сәбәпле, Гыймаз кире Бондюгка кайтып китә. 1918 елда ул Алабуга шәһәре янындагы сугышларда катнаша, Көнчыгыш фронтының 2нче армия штабы сәяси бүлеге сәркатибе ярдәмчесе итеп билгеләнә. 1918-20 еларда исә, Казан шәһәре башкарма комитеты әгъзасы һәм юстиция бүлеге мөдире, кассацион трибунал рәисе булып тора. 1921-22 елларда ТАССРның юстиция халык комиссары, 1923-25тә прокурор вазифаларын башкара. 1923 елда Гыймаз Баһаветдинов Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына читтән торып укырга керә. 1926-28 еeларда ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе урынбасары һәм секретаре, 1928-30 елларда – ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе урынбасары, эчке эшләр халык комиссары. Нинди генә хезмәт урынында көч куймасын, кайсы гына вазифаны башкармасын, Гыймаз Баһаветдинов һәрвакыт аңа гына хас иҗади күтәренкелек, дәрт белән эшли.




1929 елдан ул – Казан дәүләт университетында фәнни хезмәткәр. Кечкенәдән, химия заводы лабораториясендә инженер-химикларга химикатлар биреп торганда ук, Гыймаз белемгә омтылыш белән янып яши. Ниһаять, максатына ирешә. 1930 елда ул КДУны тәмамлый һәм химик дипломы ала. Шул ук елның февралендә университетның физика-математика факультеты деканы урынбасары итеп билгеләнә. Шул ук елның 7 мартында Гыймаз Баһаветдинов Казан университеты ректоры урынбасары була, соңрак ректор хезмәтенә күчерелә. Ректор вазифасын ул 1930–1931 елларда башкара. Шул рәвешле әлеге шәхес университытыбыз елъязмасына беренче татар ректоры булып кереп кала.



30 елларда ул матбугатта актив басыла. Ни кызганыч, Сталинның 1937-38 елгы репрессия дулкыны Гыймаз Баһаветдиновны да читләтеп узмый: 1938 елның маенда ул атып үтерелә һәм 1957 елда гына аклана. Университетның беренче татар ректоры Казанда Бауман урамы, 45 йорт адресы буенча яшәгән.

● Хәйрия эше

# Әти-әниле үксез сабыйлар

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Сүзем Дербышки бистәсендә урнашкан интернатта көн күрүче балалар турында. Математика һәм механика институтының күптәнге традициясе бар. Без һәр елны Дербышкида урнашкан балалар йортына барып, андагы сабыйларның күңелләрен күреп, онытылмаслык бәйрәм оештырып кайтабыз. Шушы көннәрдә, институтыбызның социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары П.Г.Великанов, укытучыбыз Э.Җ.Хөсәенова җитәкчелегендә бурычыбызны үтәп кайттык.

«Көннәр якты булсын өчен, йокы татлы булсын өчен,әникирәк».– дигән шигырь юлларын шул көннән бирле эчтән генә кабатлап йөрим. Чыннан да, әни янда булса, дөнья рәхәт, ләкин моның кадерен белмәүчеләр дә бар бит. Проблемага төрлечә карарга була. Яныбызда зур хөрмәткә лаек, олы йөрәкле, безне яратучы әниләр бар, шуңа күрә без бик бәхетле. Кызганычка каршы, бу бәхеттән мәхрүм балалар да аз түгел. Бу очракта сүз кәеф-сафа коруны барыннан да өстен куеп, бала тәрияләүне зур мәшәкать, авыр йөккә санаган әти-әниләр турында. Нәтиҗәдә балалар йортлары, алар белән бергә ятим сабыйлар саны елдан-ел арта. Дербышки интернатында да ике йөзгә якын бала исәпләнә.

Интернат капкаларын ачуга, тәрәзә шакып, сәлам бирүче балаларны күрү тәэсирләрен гади сүзләр белән генә аңлатып булмый. Алар һәр кешене шулай каршы ала икән. Нарасыйлар кем килсә дә, нәрсә алып килсә дә сөенә. Аларга, бүләктән бигрәк, җылы караш, наз, ягымлы сүз, ана кочагы җитми. Без, үз чиратыбызда, балаларга карата игътибарлы, назлы булырга тырыштык. Алар өчен кызыклы тамаша оештырдык: әкиятләрдән өзекләр, мавыктыргыч уеннар, җыр-бию балаларның актив катнашуы белән үрелеп барды. Һәркем үз сәләтен күрсәтергә ашыкты. Кемдер матур итеп рәсем ясый, кемдер оста итеп бии... Безнең чыгышларны карап, шаярышып утырдылар. Күзләрендә шатлык чаткылары яна башлаган сыман тоелды. Алып килгән бүләкләргә дә сөенеп туймадылар. Бәхетле мизгелләр тиз узса да, балалар күңелендә озак сакланыр, дип уйлыйм.



Анда барып кайткач, әти-әниеңнең, тормышның һәм сәламәтлегеңнең кадерен ныграк аңлый башлыйсың икән. Алардан да мөһимрәк әйбер булмавына кат-кат төшенәсең. Интернаттагы һәр сабый үз гаиләсе белән үз өендә, тормышның һәр көненә, һәр мизгеленә сөенеп яшәсен иде дә бит...

● Тарих сәхифәләреннән

*1953:*

7 апрельдә XIII Университет спартакиадасына нәтиҗәләр ясала: I урын – физика-математика факультеты, II урын – тарих-филология факультеты, III урын – геология факультеты.

*1963:*

5 апрельдә География факультеты деканы вазифасына доцент А.П.Депков билгеләнә.

12 апрельдә Университетның роман-герман телләре кафедрасына нигез салына.

13 апрельдә, Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы боерыгы нигезендә, Университетта үсемлекләрне системалаштыру һәм геоботаника, икътисади география һәм физика географиясе кафедралары берләштерелә.

*1983:*

13 апрельдә География факультеты деканы вазифасына Ю.П.Переведенцев билгеләнә.

14 апрельдә СССРның Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы боерыгы белән, Югары уку йортларының ректорлар советы турындагы нигезләмә раслана.

*2003:*

11 апрельдә, уку барышының нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, КДУның Яр Чаллыдагы филиалында уку-укыту-методика бүлеге оештырыла.

● Галәм киңлекләре


# «Гагарин кайтканмы әллә?»

**Нурсөя МИНЗИНА,**
татар филологиясе бүлеге

Бик көттереп, зарыктырып булса да, яз киләсе итте, бугай. Күңелем язгы һавага сусаган булган икән: җиһанны кочасы, көләсе, шаярасы килә башлады.

Шаяру дигәннән, җае да чыгып куйды. Һәркем белә: 12 апрельдә авиация һәм космонавтика көнен билгеләп үттек. Шул бәйрәм уңаеннан, социаль челтәрдә студентлар арасында гадәти булмаган сораштыру үткәрергә уйладым.

Мәсьәләгә традицион булмаган ысул белән якын килергә булдым. «Ул язгы иртәдә ракета белән 1 сәгать 48 минутта, бөтен җир шарын әйләнеп, Саратов өлкәсенә төшеп утыра», – дигән җөмләне респондентларыма яздым һәм аларның бу җөмләгә карата фикерләре белән кызыксындым. Җавап бирүчеләрнең күбесе сораштыруда катнашканнарын аңламый да калдылар, ахры. Нәтиҗәдә ни килеп чыкканын, җавапларны беләсегез киләме? Алайса, киттек!




Кемдер язгы иртәдә ракетада, 1сәгать тә 48 минут эчендә бөтен җир шарын әйләнеп чыккан да Саратов өлкәсенә утырган. Дөресме?

Кем соң ул, кайда? ☺

Вакытым юк килде-китте әйберләр язарга!!!

Вот молодец ул! Мин аңламадым? ☺

Гагарин кайтканмы әллә? ☺

Бик молодец кеше! Минем кебек кызу кеше икәне күренеп тора! Ни өчен Казанга түгел, ә Саратов өлкәсенә төшүе генә аңлашылып бетми...

Без аны сагынып көттек!

Бу, әлбәттә, 12 апрель көнне беренче тапкыр галәмгә очкан кеше – Юрий Гагарин турында!

Миңа калса, моны бераз хыялыйрак кеше язган. Чөнки ракета белән җир шарын әйләнеп чыгу реаль түгел кебек. Ракетада оча торган кешеләр, минемчә, чыдам, бик көчле рухлы. Һәркем дә мондый адымга бара алмас иде. Шунысы игътибарны җәлеп итә: очучының кайчан һәм күпме вакыт җиһанда булуы билгеле.

Бер түгел, ике әйләнсен! Минем анда ни эшем бар?!

Менә шундыйрак җаваплар алдым. Күрүебезчә, кемнендер кәефе булмаган, ә кемдер минем кебек уенга бирелеп, теләп язган. Белмәгәннәр белсеннәр: бу җөмлә Советлар Союзы гражданины Юрий Гагарин турында иде.

• Аклы-каралы дөнья

Китапларны сәяхәткә җибәрү турында ишеткәнең бармы? Ил буйлап түгел, әлбәттә, ә билгеле бер шәһәр, төбәк, район буенча. Юкны сөйләмә әле, дияргә ашыкма! Хыял, теләк һәм максат булганда, күп әйберләрне тормышка ашырырга мөмкин бит.

# Китаплар да сәяхәт итә!

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



### Китапка урын юк, дисәң

Барыбызга таныш булган вәзгыять: син күптән теләгән китабыңны сатып алдың, рәхәтләнеп укыдың һәм «тузан җыярга» шкафка тыгып куйдың. Ә нишләргә кала соң тагын – ташларга җәл, ә эчтәлеген инде яттан беләсең? Менә шундый очракларда күпләр хәзер «буккроссинг» дигән агымга кушыла икән. Аның асылы шунда: укып бетергән китапны буккроссерларның махсус сайтында теркисең, бирегә аңа билгеле номер бирелә. Шуны китапка ябыштырасың һәм «сәяхәткә» җибәрәсең.

Гадәттә мондый китапларны халык күп йөри торган җирләрдә яки «куркыныч булмаган урыннарда» табарга була. Әгәр сиңа шундый китапны эләктерү бәхете елмайса, сайтка кереп, әлеге китапка ябыштырылган номерны язып калдырырга кирәк булачак. Мондый алым ярдәмендә син кулыңа төшергән «белем чишмәсе»нең хуҗасы үз китабының кем кулында һәм кайсы шәһәрдә булганын белә ала. Шуны да онытма: китапны укып бетергәннән соң, аны яңадан кайдадыр калдырырга кирәк булачак. Буккроссерлык агымының мәгънәсе шуннан гыйбарәт – китап, кулдан-кулга күчеп, сәяхәт итәргә тиеш.

### Чишмә башы

Буккроссингны интернет-технологияләр белгече Рон Хорнбекер уйлап чыгара. Башта ул агымның асылын аңлата торган язуларны китаплар эченә тыгып, 20ләп «белем чишмәсе»н үз отеленең холлында калдырып китә. Ярты елдан соң, буккроссерлар саны инде 300 кешедән арткан була.

Бүген әлеге агым шактый популярлашкан. Россиядә, Италиядә, Франциядә, Америкада китапларын ирекле сәяхәткә җибәрүчеләр саны көннән-көн арта бара. Италиядә исә буккроссинг аеруча киң җәелгән. Биредә бу агымга хәтта зур дәрәҗәле кешеләр дә керешеп китә икән. Мәсәлән, Флоренция депутатлары буккроссерларга 4 меңгә якын китап бүләк иткәннәр. Шулай ук әлеге агымны популярлаштыруда журналистларның да роле зур. Италия радиостанцияләренең берсендә әлеге агымга багышланган аерым тапшыру да чыгып килә. Ә Америкадагы радио ди-джейлары бу агымны билгеле бер уенга әйләндергәннәр. Эфирда табылган китапның коды һәм урыны әйтелә, ә буккроссер хуҗасыз китапны тапкан вакытта кичергән хисләре белән бүлешә.

### Казан чынбарлыгы

Казанда буккроссинг агымы әле туып кына килә. Көннәрнең берсендә, интернетта һәм басма матбугатта «Китапларны алыштыру» дигән белдерүләр күренә башлагач, кешеләр кызыксынып китә һәм шулай итеп буккроссинг нигез салына. «ВКонтакте» сайтында аның махсус төркеме дә булдырыла. Биредә булган китапларның исемлекләрен калдыралар, агымны популярлаштыруга бәйле фикерләрен җиткерәләр.

Зур-зур шәһәрләрдә буккроссинг дигән агым елдан-ел популярлаша. Мәскәүдә, Санкт-Петербургта китап сөючеләр саны берничә дистә мең. Ә Казанда буккроссинг белән мавыгучылар алай ук күп түгел. Сәбәбе нәрсәдә? Татарстанда буккроссингка реклама җитеп бетми. Мәсәлән, минем танышларым арасында да бик күп кеше китапларны яратып укый, әмма буккроссинг дигән сүзне ишеткәннәре юк. «Нәрсә соң ул?» – дип сорыйлар.

Бездә буккроссингның чәчәк атмавына кешедәге шикләнү хисе дә гаепле. Яхшы, кыйммәтле китапларны бар кеше дә «сәяхәткә» җибәрергә риза түгел. Шуңа да бездә әллә ни кызык булмаган, кирәксез китаплар белән генә «хушлаша»лар. Ә андыйларны укырга теләүчеләр дә аз шул.

Ә менә китапны кулга төшерү өчен «куркыныч булмаган урыннар»ны тәкъдим итүче Андрей Анисимов фикеренчә, башкалабызда буккроссинг озакламый бөтенләй бетәчәк. «Мондый юл белән китап уку хәзер кызык түгел инде. Кеше әкренләп электрон китапларга күчеп бара», – ди егет.

Мин дә буккросерлар рәтенә кердем әле. Бер китапны «сәяхәткә» җибәрдем һәм үзем дә бер кыздан укырга алдым. Кызык икән ул китаплар алмашу! Әбәлки, безгә татар буккроссингын башлап җибәрергәдер?..

***P.S.*** *Казанда китапларны түбәндәге* ***«куркыныч булмаган урыннар»****дан алырга, калдырырга мөмкин:*

***«Амакс Сафар-отель»*** *кунакханәсе. Берьяклы Гривка урамы, 1нче йорт;*

***«Книжный Двор»*** *кибете. Спартаковская урамы, 2 йорт.*

***ТРның Милли китапханәсе.*** *«Куркыныч булмаган» китап киштәләре китапханәнең Кремль урамындагы беренче бинасында, К.Маркс урамындагы икенче бинасында һәм Театральная урамындагы өченче бинасында бар.*

• Киңәш-табыш

# Имтиханга ничек әзерләнергә?

Киңәшче ролендә – **Ләйсән ИСХАКОВА**

Сессия дә килеп җитте. Ә син әле әзер түгел һәм нидән башларга белмисең? Димәк, киңәшләребез нәкъ синең өчен!



✔ Планлаштыр! Вакытыңны дөрес бүләргә өйрән. Буш вакытың булу белән, лекцияләреңне ал да укырга тотын!

✔ Ничек истә калдырырга? Еш кына шулай була: лекцияне укыйсың һәм инде 10 минуттан берни истә түгел. Моны булдырмас өчен, иң мөһим, кирәкле тоелган фикерләрне аерым дәфтәргә конспект рәвешендә теркәп бар. Язганда, күру хәтере дә эшли. Язганнарыңны кычкырып уку исә тагын да яхшырак. Бу очракта ишетү хәтере дә эшкә җигелә.

✔ Имтиханны арган баштан бирү авыр, шуңа төне буе укып утырудан мәгънә булмаячак. Яхшылап ял ит!

✔ Имтихан иртәсе. Конспект турында хәтерлисеңме? Анда барысы да кыска һәм аңлаешлы итеп язылган. Әнә шул мәгълүматны тагын бер кат укып чык, чөнки иртән мәгълүмат әйбәтрәк үзләштерелә.

✔ Шпаргалка язу да файдага булачак. Әлбәттә, бу сине җавваплылыктан азат итми, барыбер укырга, өйрәнергә туры киләчәк. Шулай да, шпаргалка язганда, материалны тагын бер кат кабатлау мөмкинлеге туа.

✔ Әзерлекне иң авыр сораулардан башла. Укытучың, һичшиксез, белемеңне бәяләячәк!

✔ Үз-үзеңә ышаныч – уңыш чыганагы. Каушама, үзеңне тыныч тот. Юкса, сораугa җавапны белгән очракта да, уңышсызлыкка дучар булырга мөмкин.

Ни генә булмасын, әзерлекне соңгы көнгә калдырма. Һәр имтиханга җаваплы һәм җитди итеп әзерлән. Уңышлар!

• Рульдә бичә

# Әй, машина, машина...

Нәзирә **ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-МОСТАФИНА**

Әлеге язмам үз машиналарында укырга килүче студентлар һәм машиналы укытучылар өчен файдалы булыр, дип уйлыйм.

Шәһәр үзәгенә килдең исә, машинаңны кесәңә тыгып куясың килә башлый. Кая карасаң да, «туктап торырга ярамый», «машина куярга ярамый» дигән юл билгеләре эленеп тора. Ә көн саен эшкә йөрергә кирәк, җәмәгать. «Җәяү йөр!» диярсез сез. Өй белән эш арасы якын булса, бик рәхәтләнеп йөрер идем дә, шәһәр үзәгеннән ерак яшибез шул. Шуңа да, шәһәр эчендә машинада йөрүнең бөтен «тәмен татып» «рулит» итәргә кала.

Бөкедән тыш, машина йөртүчеләрнең тагын бер дошманы – чокыр-чакырлар. Шәһәребезнең кайбер урамнары яңа гына бомбага тоткан урыннарны хәтерләтә. Берәз гына тизлегеңне арттырдың исә, тәгәрмәчсез, юк ла, машинасыз каласың. Иң куркыныч тагын бер «дошман»: камералар һәм эвакуаторлар. Камералар дигәннән, халык аларга ияләшә төште инде. ГИБДДдан бер-ике «сәлам хаты» алганнан соң, руль артында йөрүчеләр берберләренә антирадарлар бүләк итештеләр. Кызганыч, ә менә эвакуаторлар белән көрәшү ысуллары уйлап табылмаган әле...

Беркөн шулай өйгә кайту нияте белән эштән чыктым. Күрәм, машинадан җилләр искән. ГИБДДда эшләүче танышым минут эчендә машинаның Спартаковская урамындагы штрафстоянкада булуын хәбәр итте. Беренче эш итеп, штрафстоянкага барасы икән. Килеп җиту белән, эт оясы кадәр будкада синең кулыңа протокол тоттыралар. Шуның белән Оренбургский трактка җилдерәсең. ГИБДД кичке алтыга кадәр генә эшли, ягъни рөхсәт кәгазен бирә. Әгәр аны ала алмасаң, машина штрафстоянкада төн куна, кемнендер калын кесәсенә күп итеп акча тама. Билгеле инде, күбесенең машинасы стоянкада йоклап кала. Кеше кичкә биштә-алтыда өйгә кайтырга кузгала, шул вакытта машинасының юклыгын күреп, аны эзләргә керешә. ГИБДД хезмәткәрләре дә вакытны махсус суза. Шул рөхсәт кәгазен язганда да дүрт-биш тапкыр каядыр чыгып керә. Кәгазьне кулыңа тоттыргач, теге эт оясына йөгерәсең.

Штрафстоянкадагы корылманы эт оясына охшатуымны, зинһар, гафу итә күрсеннәр – дөресе шул. Зурлыгы ике метрга ике метр. Халык күп, чөнки штрафстоянка көненә ике йөзләп машина кабул итә. Эвакуаторлар шәһәр үзәгендә бал кортлары кебек тыз-быз йөреп кенә тора. Протокол төзүче хезмәткәрнең язуы хастаханәдәге табиб язуын хәтерләтә. Шаһитлар таба да алар өчен проблема түгел, такси йөртүче егетләр ярдәмгә килә. Ә тегеләре, үз чиратында, таксистларга, юл читендә туктап, клиентлар көтәргә рөхсәт итәләр. Мескен хуҗа машинасын тиешле урынга куймаган өчен 1500 сум (кагыйдә бозуның нинди булуына карап, 1000нән 5000 сумга кадәр), эвакуатор хезмәте, машинасының штрафстоянкада саклануы өчен, матур гына сумма түли. Анңары Казан шәһәренең тишек юллы урамнарыннан өенә таба юнәлә. Республика, ГИБДД җитәкчелеген сүгеп, бер-бер артлы сораулар бирә: «Машиналарны кайда куярга?!», «Кайчан тигез, сыйфатлы юллардан йөрербез?!», «Без түләгән зур суммадагы штраф акчалары кая китә?!»



DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.